# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«21» ноябрь 2024 ел № 4**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, 2024 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (универсаль спорт мәйданчыгы -2 өчен киртә төзү һәм инвентарь сатып алу);
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү (күл территориясен тигезләү һәм чистарту, янәшәдәге территорияне яшелләндерү һәм кече архитектура формаларын урнаштыру - ял итү өчен эскәмияләр, чүп савытлары)

“ӘЙЕ” “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 190 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 98 кеше тавыш бирде; " Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл

җирлегендә Урта Бирәзә авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (универсаль спорт мәйданчыгы -2 өчен киртә төзү һәм инвентарь сатып алу);
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү (күл территориясен тигезләү һәм чистарту, янәшәдәге территорияне яшелләндерү һәм кече архитектура формаларын урнаштыру - ял итү өчен эскәмияләр, чүп савытлары)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» -98 « КАРШЫ»-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге башлыгы Шакирова И.Р